

# *КАЛӘМ ТИБРӘТҮЧЕЛӘР*

**№2 2019 ел**

***<u>98нче татар – рус урта гомуми белем бирү мәктәбе</u>***

**Мәктәбем! 80 еллык юбилееӊ белән сине!**




**Әй, мәктәп, мәктәбем! Кем генә моӊлы кыӊгырау тавышын сагынып кабат сиӊа килми дә, кем генә үткән балачагыныӊ бәхетле мизгелләрен, яраткан укытучыларын искә алмый икән?!**

**Мәктәбемә илтер юллар буйлап**

**Бала булып килә узасым.**

**Еллар үткәч килә: -Исәнме!-дип,**

**Балачакка кулым сузасым.**

**«Дөнья тормышының рәхәтлеге күләгә кебек – без аны теләмичә алга йөгерсәк, ул арттан килә, ә инде тотынырга теләсәк, ул кача.”**

**(Сәгъди Хаҗи)**

Мәктәбебезнең юбилеен каршылаган көннәрдә нәкъ менә шундый уйлар киләдер бүген безгә, олыларга. Һәрберебезнең балачак, мәктәп елларына кире кайтып, яңадан һафасыз шаян егет, кыз булып, мәктәп коридорларыннан бер йөгерәсе, яшь буынга карап: “Эх, рәхәтегезне тоя белмисез” дип әйтәсе киләдер, мөгаен. Ни өчендер нәкъ менә шушы мәктәп еллары һәр кешенең күңелендә басылып кала, еллар үткән саен артка борылып карарга өнди. Быел мәктәбебезгә 80 ел тула. Азмы ул, күпме? Моны бары тик мәктәпнең кеше күңелендә тоткан урыны белән генә билгеләп буладыр.

Мәктәп һәм укытучы! Бу сүзләр һәркем өчен иң мөкатдәс сүзләр булып кала! Минем өчен бу сүзләр һәрвакыт иң бөек мәгънә йөртте. Сыйныф җитәкчемә сокланып, кайчандыр укытучылык юлыннан киттем, хәзер исә мин – мәктәпне һәр укучыга – туган йорт, мәктәп коллективын – гаилә итәргә тиешле кеше. Безнең мәктәп моңа чыннан да лаеклы, күп кенә укытучылары шул ук мәктәпне бетереп, яңадан монда эшләргә килгән затлар, кайчандыр чыгарылыш сыйныф укучылары – хәзер инде үз балаларын безнең 98нче мәктәпкә йөртәләр. Шундый тирән тарихлы мәктәпне ничек хөрмәтләп, кире кайтмыйча була? Ә мәктәбебезнең тарихы чыннан да киң!

1935 нче елның 23-25 августында үткән Казан шәһәр Советы президиумы утырышының 39нчы номерлы беркетмәсендә яңа мәктәп төзелеше турында карар чыгаралар. 98 нче мәктәптә дәресләр 1939нчы елның 1 сентябрендә башлана. Бөек Ватан сугышы елларында мәктәптә госпиталь урнаша, укучыларны исә башка мәктәпләргә җибәрәләр. Шул яшь бала-чага да җиңүне якынайтуга үз өлешен кертә: яралылар алдында җырлар белән чыгыш ясыйлар, мәктәп ашханәсе өчен алма, яралыларга витамин буларак кулланырга дип нарат ылысын, можжевельник җимешләрен җыялар.

Сугыш елларыннан соң мәктәп беразга хатын-кызларныкына әйләнә. 60нчы елларда инде исә мәктәпнең исеме спорт җиңүләре белән яңгырый. Безнең “Орбита” спорт клубы күп ярышларда җиңүче була. Мәктәп директоры Алексей Николаевич үзе балалар белән хоккей уйный – аларны мавыктыра. “Орбита”ның 50 еллыгына инде мәктәптә спорт музее ачыла. 1982нче елда Башкарма комитет карары белән Казан шәһәренең Вахитов районы 98 нче номерлы мәктәбенә 640 урынга исәпләнгән янкорма төзүне кабул итә. Хәзер яңа бинада башлангыч сыйныфлар укый.

Ел саен мәктәптә Татарстан Республикасы Бөек Ватан сугышы партизаннарының традицион очрашуы уза, мәктәп базасында республикабызда бердәнбер булган Партизан музее эшли. 1985нче елда әлеге музейга безнең мәктәптә 40 елдан артык тарих укытучысы булып эшләгән Валентина Алексеевна Федорова нигез сала. 1993нче елда мәктәп татар-рус мәктәбе статусы ала. Ә 2005нче елның 1 сентябреннән хәзерге вакытка кадәр гамәлдә булган милиция сыйныфлары ачыла.

Мәктәптә хәзер дә “Юная Россия”, “ФОРТПОСТ” хокук саклау отрядлары эшли. Укучыларыбыз даими рәвештә спорт ярышларында, армия слетларында катнаша. Вакыйгалар алга таба ничек барыр, вакыт күрсәтер. Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк дигән борынгылар. Ә синең үткәнең данлы, киләчәгең якты, и, минем мәктәбем!

**мәктәбебез директоры Авзалова Айгөл Илдаровна**




80 яшь тула мәктәбемә,

Зур юбилей! Узган зур гомер.

Ничә буын синдә белем алган,

Изге теләк теләгән күңел.

80 еллык матур тарихың бар,

Шәкертләрең синең җитәрлек.

Арасында шундый зур шәхесләр,

Дан казанган, исең китәрлек.

Мәктәп-туган җир җылысын бирүче, балачак һәм үсмер еллар истәлеген саклаучы, еллар дәвамында үзенә чакырып, олылап каршы алучы изге йорт ул. ”Үз мәктәбенең тарихын белмәгән кешенең киләчәге өметсез”,- дибез. Безнең мәктәбебез тарихы еракларга барып тоташа. Мәктәп 1939 нчы елда төзелә. Ә инде Бөек Ватан сугышы башлангач, мәктәп укучыларын башка күрше мәктәпләргә күчерәләр һәм безнең мәктәп 1941-1943 нче елларда госпиталь хезмәтен башкара. 1944 нче елда укыту яңадан торгызыла. Мәктәбебез белемле һәм талантлы укытучылары белән шул елларда ук дан тота. Мәсәлән, химия укытучысы Лебедева Антонина Артемьевна; атказанган укытучы Кожевников Георгий Сергеевич; рус теле һәм әдәбияты укытучысы Разумовская Мария Андреевна; шулай ук 18 яшьтә өлкән вожатый булган, аннан соң институт бетереп гомер буе рус теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшләгән, тәрбия эше буенча директор урынбасары вазифасын да алып барган, гомумән, гомеренең 60 елын балалар белән эшләүгә багышлаган Надежда Ивановна Обыденова; шушы мәктәптә укып, институтны тәмамлаганнан соң туган мәктәбенә кайтып, гомеренең соңгы көннәренә кадәр шушы мәктәптә эшләгән Евстратова Ангелина Михайловна.

Мәктәбебездә бушка төрле түгәрәкләр үткәрелгән: драма, гимнастика, хор, әкият һәм тарих, химия, физика фәненнән түгәрәкләр. 60 елларда мәктәп спорт буенча уңышлары белән дан тоткан. Мәктәптә” Орбита” спорт клубы эшләгән һәм бик күп кенә ярышларда югары үрләр яулаган. “Орбита”ның 50 еллыгына мәктәптә музей ачылган. Мәктәпнең биологлары мәктәп яны территориясендә зур эш башкарганнар. Алар анда яшелчә, җиләк-җимеш утыртканнар. Ә инде мәктәп бакчасында үстерелгән уңышлар ашханәдә балалар ашатуга тотылган.

Шулай ук мәктәбәбезнең кайбер укучылары укытучы һөнәрен үзләштереп нәкъ менә үзләре укыган мәктәпкә кайтканнар. Мәсәлән, Иванова Наталья Евгеньевна- башлангыч сыйныф укытучысы, хезмәт стажы- 36 ел; Назарова Марина Валентиновна- башлангыч сыйныф укытучысы, хезмәт стажы- 37 ел; Барашкова Ольга Алексеевна- физкультура укытучысы, хезмәт стажы-38 ел; Худякова Ольга Сергеевна- музыка укытучысы, хезмәт стажы-38 ел.

Гомер буе шушы мәктәптә генә эшләүче укытучыларыбыз да бар: Трофимова Мария Алексеевна- башлангыч сыйныф укытучысы, хезмәт стажы -40 ел; Сагъдатуллин Габбас Габделбариевич- физкультура укытучысы, хезмәт стажы- 30 ел; Усманова Наилә Фирдусовна-башлангыч сыйныф укытучысы, хезмәт стажы- 36 ел; Фаридова Фәнисә Наиловна-математика укытучысы, хезмәт стажы- 35 ел; Топыркина Татьяна Павловна- география, биология укытучысы, хезмәт стажы- 31 ел; Касыймова Гөлнур Наил кызы-татар теле һәм әдәбияты укытучысы, хезмәт стажы-22 ел.

Менә шулай, гомер аккан су кебек акрын генә үтеп бара. Мәктәп еллары һәркем күңелендә якты хатирә булып саклана. Беренче кыңгырау, беренче сыйныфка аяк басу, беренче дәрес, беренче укытучы... Мәктәп турындагы хатирәләребезнең иң түрендә –әлбәттә инде-укытучылар! Мәктәбебез белән бәйле олы җанлы, киң күңелле, ярдәмчел укытучылар! Шушы мәктәптән нинди генә атаклы кешеләр чыкса да, алар, иң беренче чиратта, үзләренең укытучыларына бурычлы!

Бүгенгесе көндә мәктәбебездә 54 укытучы хезмәт куя. Кайсы гына кафедраны алсаң да, һәрберсендә тырышып, үз эшен җиренә җиткереп эшләүче укытучылар эшли. Мәктәбебез директоры Авзалова Айгөл Илдаровна яшь кенә булуына карамастан, мәктәп һәм коллектив белән бик оста, грамоталы, үз эшен белеп идарә итә.

Быел мәктәбебезнең 6 укытучысы «Безнең яңа укытучы-– 2019» гранты җиңүчеләре булдылар.

Матвеева Ангелина Владимировна, башлангыч сыйныф укытучысы;
Натекина Кристина Юрьевна, тарих укытучысы;
Хамитов Талгат Рашидович, математика укытучысы;
Хасанова Лидия Ренатовна, инглиз теле укытучысы.
Шулай ук “Укытучы–мастер» номинациясендә Адылова Дильбар Абриковна, ә “Укытучы-наставник” номинациясендә Марьина Елена Павловна җиңү яулады.
Алга таба да мәктәбебезгә һәм укытучыларыбызга уңышлар теләп калабыз!

Мәктәп сукмагыннан атлый-атлый,

Күпме вакыт, еллар үтелгән.

Күңел түребездә истәлекләр

Түкми-чәчми канга сеңелгән!

Гомер буе якты нур өләшеп,

Белем биреп, биреп тәрбия,

Укытучы һөнәрен һәрчак зурлап

Күпме кеше безгә баш ия!

Сокланырлык гомер кичерәбез,

Балалар дип янып яшибез.

Олы җанлы, киң күңелле, якты

Фәрештәгә тиңләр кеше без!

**югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

**Касыймова Гөлнур Наил кызы**

**Мәктәбем**

Иртән-иртүк торам да мин
Сагынып мәктәпкә барам.
Сумка тулы дәреслекләр,
Белем алам алардан.

Күңелле соң мәктәбемдә,
Укыйбыз, ял итәбез,
“Ашау эшне калдырмый,”- дип,
Тәмләп ашап менәбез.

Менә шулай үтә безнең
Мәктәбебез еллары.
Белем иленә атлыйбыз
Башны күтәреп югары.

**4В сыйныф укучысы Набиуллина Сәгадәт**



**Кояш илне яктырта, уку-кешене**

**Мәктәп- безнең икенче туган йортыбыз**

Әйе, чыннан да, беренче сыйныфка укырга кергән вакытта, безнең алдыбызда мәктәп белем дөньясына сәяхәткә чакырып үзенең ишекләрен ача. Без күп кенә шагыйрьләр, язучылар, галимнәрнең тормыш юллары, иҗатлары белән танышабыз. Ә бит аларның да тормышы нәкъ менә безнең кебек башланып киткән.

Безгә хәтле монда күп кенә балалар укыган. Алар арасында укытучылар, табиблар, тренерлар, очучылар, юристлар, кибетчеләр, хисапчылар һәм башка бик күп һөнәр ияләре бар.

Күп кенә конкурсларда, олимпиадаларда җиңеп без мәктәбебезнең рейтингын күтәрәбез. Шуңа күрә дә безнең мәктәп Казан шәһәрендә 1 урында тора.

Кешелек хәтере гомерлек түгел, нниндидер вакыйгаларны без онытып җибәрергә мөмкинбез. Ләкин без икенче туган йортыбыз булган, белем алган мәктәбебезне беркайчан да онытмаячакбыз! Кызыклы дәресләр һәм дәрестән тыш чаралар дисеңме, дәресләрдән соң үткәрелә торган түгәрәкләр-болар барысы да безнең өчен бит!

Без әлеге мәктәптә укуыбыз белән горурланабыз! Шушы юбилей елында без аның тагын да чәчәк атуын теләп калабыз! Мең ел яшә, туган мәктәбем!

Белем сукмагыннан атлый-атлый,
Һәр көн саен алга барабыз!
Рәхмәтебез сиңа чиксез безнең,
Елдан-ел без үрләр алабыз!

**7Б сыйныф укучылары Халилова Нармин һәм Осипченко Арина**

Укытучы белән әни сүзен

Йөртер идем мин гел янәшә.

Өйдә әни, мәктәпләрдә апа

Әй, ягымлы итеп эндәшә.

Күзләрендә һаман хафалану,

Мең сорауга кирәк мең җавап.

Сезнең алда мәңге бурычлы без,

Рәхмәтле без бик-бик күп кабат.

Укытучы! Кем генә зур ихтирам белән телгә алмый икән бу исемне! Язучы Мәхмүт Хөсәен сүзләре белән әйтсәк:

Укытучы – олы юл башың,

Күзләреңне ачкан кояшың.

Укытучы - укучылар күңеленә якты нур сибүче, балаларга ныклы белем бирүче, алар йөрәгенә игелеклелек, намуслылык, бердәмлек, илебезгә тугърылык, ата-анага хөрмәт һәм мәхәббәт орлыгы чәчүче олы шәхес. Укытучы һөнәре җиңелләрдән түгел. Шулай да бу һөнәргә мин кечкенәдән тартылдым. Балачактан укытучы булырга хыялландым. Энемә биш, ә үземә ун яшь булган вакытта аның белән “ укытучы-укытучы” уйный идек. Мин аны укырга, язарга өйрәттем. Шулай ук мәктәптә укыганда, татар теле һәм әдәбияты укытучыбыз Мәдинә апаның туган телебез һәм әдәбиятыбызга карата мәхәббәт тәрбияли алуы да, миңа үз һөнәремне сайлаганда бик зур ярдәм итте. Һәм әлбәттә инде, әти-әниемнең укытучы булуы миңа бу һөнәрне сайлауда зур этәргеч булды. Әтием 18 ел мәктәптә физик тәрбия дәресләре алып барса, ә әнием 38 ел математика укытучысы булып эшләде. Шуның 20 елын директор урынбасары вазифасын башкарды. Әти-әниемнең авыр, катлаулы һәм зур сабырлык сорый торган хезмәтен күреп үссәм дә, мин үземнең карарымда нык тордым. Хыялымны тормышка ашыру нияте белән, 1993 нче елны Казан Дәүләт Педагогика Институтына укырга кердем. Уку дәверендә укытучы һөнәренең катлаулылыгына тагын да ныграк төшендем. Үземнең педагогик эшчәнлегемне туган авылымда татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак башлап җибәрдем. 1999 нчы елны язмыш җилләре мине Казан шәһәренең Вахитов районында урнашкан 98 нче рус-татар урта мәктәбенә алып килде. Төрле сыйныфларда татар теле һәм әдәбиятын укыту белән беррәттән, 6А татар сыйныфына сыйныф җитәкчесе итеп билгеләндем. Кечкенәдән балалар яратканга, бу балалар минем якын туганыма әверелделәр. Унбер генә бала булсалар да, унберенең унбер төрле холкы бар иде. Бу балалар белән миңа уртак тел табарга әти-әниләрнең дә ярдәме зур булды. Бергәләп Яңа ел, 23 нче февраль, 8 нче март бәйрәмнәре, төрле конкурслар, туган көннәр үткәрдек. Балаларыбызның шатлык-кайгыларын бергәләп уртаклаштык. Бүгенгесе көндә укучыларым белән күрешеп, аралашып

яшәвебез дә сыйныф җитәкчесе буларак хезмәтемнең нәтиҗәсе булып тора. Р. Эмерсон сүзләре белән әйтсәк, “Яхшы тәрбиянең нигезе- бала шәхесенә хөрмәт белән карау”. Әгәр дә балага хөрмәт белән карасаң, авыр вакытта якласаң, кирәк чагында ярдәм итсәң, билгеле, укучының сыйныф җитәкчесенә карата ышанычы зур була. Димәк, тәрбиянең нигезе бар дигән сүз.

Беренче чыгарылышымнан соң мин 5А татар сыйныфына сыйныф җитәкчесе итеп билгеләндем. Сыйныфта укучы балалар белән кайгы-шатлыкларыбыз уртак булды. 24 баланың һәрберсенең үзенә генә хас сәләте, холкы булды һәм белемгә омтылышлары бик көчле иде. Шулай ук алар үзләренең сәләтле булулары белән дә күпләрне таң калдырды. Кайбер укучыларым уртача билгеләргә генә укысалар да, бию, җыр, рәсем сәнгате белән кызыксындылар, шигырьләр иҗат иттеләр. Бу сыйныф укучыларым белән дә төрле конкурслар, бәйрәмнәр, туган көннәр үткәрдек, сыйныфтан тыш чараларда да актив катнаштык. Шәһәребезнең истәлекле урыннарына, музейларга, концерт-театрларга һәрдаим йөреп тордык. Үзем җитәкләгән “Каләм тибрәтүчеләр” гәҗитенә дә укучыларым үзләренең мәкаләләрен җибәреп тордылар. Төрле темага язылган мәкалә, әкият, шигырьләребезне«Сабантуй»гәҗитендә( журналында) басылып чыгуын күрү- безнең өчен зур бәхет һәм иҗатыбызның җимеше булып торды. Мәктәптә, районда, республикада нинди генә конкурслар булмасын, минем сыйныф укучыларым алдынгы урыннарны яулап барды.

2018 нче елда мине 7Б сыйныфына сыйныф җитәкчесе итеп билгеләделәр. Менә икенче ел инде балалар белән уртак тел табып эшлибез. Сыйныфтагы укучыларым үзләренең активлыгы, белемлелеге, иҗади булулары, конкурсларда актив катнашулары белән аерылып тора. Әти-әниләр белән дә уртак тел табып эшлибез. Алар минем һәр уйлаган эшемә һәрчак уңай нәтиҗә белән җавап бирәләр.

Менә шулай итеп, гомер аккан су кебек сизелми дә үтеп бара. Ләкин, мин укытучы һөнәрен сайлавыма һәм сыйныф җитәкчесе булуыма бер дә үкенмим. Балаларның шат елмаюлары , ягымлы карашлары күңелемә олыгаерга ирек

бирми. Киләчәктә үз һөнәремә тугъры калып, үземә йөкләнелгән бурычны җиренә җиткереп үтәрмен!

Язмышлардан узмыш юк шул,
Минем язмыш – балалар.
Белем бирү,  тәрбия кылу-
Төп бурычым булып калалар.
Балаларның шат авазы
Шифа бирә йөрәккә.
Һәрчак саулыкка төенеп
Яшәсәк иде бергә!

**югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Касыймова Гөлнур Наил кызы**



**Укытучыга рәхмәт әйтә белгән халык- үлемсез!**

***Һәр кешенең үз туган иле, тормышка юллама биргән үз мәктәбе, рәхмәт хисләре белән, олылап искә ала торган укытучылары була. Без дә укучыларыбызның фикерләрен тыңларга булдык.***

**Федотова София, Камашева Ләйлә.** Безнең яраткан укытучыбыз- Матвеева Ангелина Владимировна. Ул безнең башлангыч сыйныфта сыйныф җитәкчесе булды. 1 генә ел укытуына карамастан, без аны яратып өлгердек. Ул бик яхшы, йомшак күңелле, һәрчак кешегә ярдәмчел, шат күңелле укытучы. Аның белән бик тиз уртак тел табып була. Без аны бик сагынабыз һәм уңышлар телибез!

**Мираламов Равшан.** Минем яраткан укытучым- Топыркина Татьяна Павловна. Ул- безнең сыйныф җитәкчебез. Шулай ук ул безгә география фәнен дә укыта.Ул бик белемле, акыллы һәм төгәл укытучы. Без аның белән төрле экскурсияләргә, киноларга, музейларга, театрларга йөрибез. Аның безнең сыйныф җитәкчесе булуына без бик шат! Укытучыбызга алдагы эшендә бары тик уңышлар гына һәм саулык-сәламәтлек теләп калабыз!

**Крафт Арина, Гончарова Даша, Хайруллина Рената.** Безнең яраткан укытучыбыз- татар теле һәм әдәбияты укытучысы, безнең сыйныф җитәкчебез Касыймова Гөлнур Наиловна. Укытучыбыз һәрбер дәресне кызык, мавыктыргыч, аңлаешлы итеп алып бара. Сыйныфтагы һәрбер бала белән ул уртак тел таба белә, һәрбер эшенә җаваплы карый, бер генә баланы да ул игътибарсыз калдырмый, аларга сүзе белән дә, эше белән дә ярдәм итә. Ул үзенең эшен һәм укучыларын бик ярата. Аның күңелендә бик күп идеяләр, фантазияләр булганга күрә, без барлык конкурсларда да беренче урыннарны яулыйбыз! Ул безнең өчен янып-көеп йөрүче сыйныф җитәкчебез! Без сыйныфыбыз белән укытучыбызны яратабыз, хөрмәт итәбез һәм аңа рәхмәтебезне белдерәбез!

**Осипченко Арина.** Минем яраткан укытучыларым – Газизова Клара Ризовна һәм Ибраһимов Илназ Халитович. Клара Ризовна безгә математика фәнен укыта, бик әйбәт укытучы. Ул безгә билгеләрне төзәтергә мөмкинлек бирә. Шул ягы аның миңа бигрәк тә ошый. Шулай ук икенче яраткан укытучым-Ибраһимов Илназ Халитович. Ул яхшы күңелле, юмор хисле биология укытучысы. Илназ Халитович хайваннар ярата. Дәрестә укытучыбыз һәрбер теманы гади һәм аңлаешлы итеп җиткерә.

**Белова Ангелина, Трофимов Арслан.** Безнең яраткан укытучыбыз һәм сыйныф җитәкчебез- Аскарова Лилия Федаелевна. Укытучыбыз безгә информатика дәресен укыта. Ул дәрес темасын әйбәт аңлатучы, һәрвакыт безгә ярдәм итәргә әзер торучы бик әйбәт укытучы. Лилия Фидаелевна безнең өчен һәрчак кайгыручы, кирәк вакытта сүз белән дә, эш белән дә булышучы сыйныф җитәкчебез. Без аны бик яратабыз һәм хөрмәт итәбез!

**Хасанов Булат.** Минем яраткан укытучым- Фәнисә Наильевна. Ул безгә 5 нче сыйныфтан алып математика укыта. Фәнисә Наильевна бик көчле белемле педагог һәм искиткеч кеше. Мин аны бик хөрмәт итәм. Аңа киләчәктә саулык-сәламәтлек, эшендә уңышлар һәм гаилә бәхете телим! Безгә биргән белемнәре һәм акыллы киңәшләре өчен зур рәхмәт аңа!

**Гәҗитебезнең актив хәбәрчесе Хәсәнов Булат мәктәбебезнең берничә укытучысы белән әңгәмә үткәрде. Әйдәгез, бергәләп күзәтү ясап алыйк әле.**

- **Хөрмәтле Габбас Габделбариевич**! Сез чыгышыгыз белән кайсы яклардан һәм бу мәктәптә ничә ел эшлисез?



- Мин чыгышым белән Сарман районы Рангазар авылыннан. Бу мәктәптә 30 ел эшлим.

- Сез кечкенәдән укытучы булырга теләдегезме?

- Юк. Мин кечкенәдән хәрби булырга теләдем. Ләкин әти-әни мине ул өлкә буенча җибәрергә теләмәгәнлектән, физкультура укытучы һөнәрен сайларга булдым. Чөнки мин спортны да бик ярата идем. Спорт буенча бөтен ярышларда катнашып, гел алдынгы урыннар яуладым. Шулай ук миңа сыйныфташымның да этәргече зур булды. Ул миңа ”Син булдырасың, әйдә, физкультура укытучысына кер”,- дип киңәш бирде. Үземнең һөнәремнән , Аллага шөкер, канәгать! Канәгать булмасам, шушы һөнәремә 30 ел буе тугъры булып калмас идем.

- Сезнеңчә, укытучы нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?

- Укытучы үз эшен бик яратырга, үз өстендә эшләргә, балаларны яратырга, белемен укучыларга оста итеп җиткерә белергә тиеш.

- Сез укыткан балалар арасында сезнең өлкәдәге һөнәр ияләре бармы?

- Әйе, мәктәп директорлары, физкультура укытучылары бар.

- Мәктәбебезгә 80 яшь тулу уңаеннан нинди теләкләр теләр идегез?

- Киләчәктә дә мәктәбебез үзенең белемле укытучылары, белемгә омтылучы укучылары белән дан тотсын иде! Иң изге теләкләр телим!

**- Хөрмәтле Наилә Фирдусовна!** Сез чыгышыгыз белән кайсы яклардан һәм бу мәктәптә ничә ел эшлисез?



-Мин чыгышым белән Апас районы Балыкчы авылыннан. Бу мәктәптә 26 ел эшлим.

- Сез кечкенәдән укытучы булырга теләдегезме?

- Язмыштыр дип уйлыйм. Кечкенәдән үк балалар яраттым. Миндә тәрбияче дә, укытучы да булу теләге бар иде. Ләкин тормыш сукмагы мине шушы укытучы юлыннан алып китте. Бу һөнәрне сайлаганыма бер дә үкенмим.

-Сезнеңчә, укытучы нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?

-Минемчә, укытучы балаларны, эшен яратырга, үз һөнәренә тугъры булырга, нинди генә очракта да кешелекле, үз фәнен бик әйбәт белүче булырга тиеш.

-Сез укыткан балалар арасында сезнең өлкәдәге һөнәр ияләре бармы?

- Әйе, бар. Башлангыч сыйныф укытучысы, каратэ буенча тренер, тарих, җәмгыять белеме укытучысы бар.

- Мәктәбебезгә 80 яшь тулу уңаеннан нинди теләкләр теләр идегез?

- Мәктәбемне бик яратам. Аны 80 яшьлек юбилее белән тәбрик итәм. Киләчәктә дә зур уңышларга ирешеп яшәргә язсын! Җитәкчеләремә, хезмәттәшләремә саулык-сәламәтлек, кояштай озын гомер, күңел тынычлыгы, гаиләләрендә иминлек, эшләрендә зурдан-зур уңышларга ирешүләрен теләп калам! Киләчәктә дә шулай дус, тату булып эшләргә язсын!




“Яхшы укытучыга бары ике сыйфат җитә: зур белем һәм олы йөрәк.”

Л.Н.Толстой

“Мәктәп-укучылар саны белән түгел, ә аларның уңышлары белән данлыклы”

Н.И.Пирогов

“Укытучылар тырышлыгы-ил бавыры ныклыгы”

С. Поварисов

Укытучының һәр сүзен мәхәббәт белән үтә.

Ризаэддин Фахреддин

Укытучы булып туарга кирәк.

Халык сүзләре

Язмыш синең  тез астыңа китереп сукса-егылмас өчен якасына ябыш. Утларга салса-үзең аннан да көчле ян, шулвакыт аның кызуын сизмәссең. Суларга ташласа-күбек булып өскә күтәрелмә,- асылташ булып төпкә бат, ялтыравыңны күреп, чумып алырлар. Тузан итеп Һавага күтәрсә-яңгыр тамчыларына кушылып, җиргә төш. Карурманнарда адаштырса, кояшка карап юл сайла. Ташлар белән бастырса-чишмәгә әверелеп, ireккә ургы. Җиргә күмсә—орлык шикелле тишелеп  чык. Җилкәнеңне җилләр екса-йөрәгеңне җилкән итеп күтәр. Нинди генә очракта да җиңәргә өйрән. Көчле рухлылар гына максатларына ирешә алалар. Түземнәр генә бәхеткә лаек!

Фәнис Яруллин

**Мәктәбебез вакыйгалары:**

1. Октябрь аеның өченче атнасы бөек рус шагыйре, язучысы, драматургы, рәссамы М.Ю.Лермонтовка 205 яшь тулуга багышланды. 6-9 нчы сыйныфларда китапханә дәресләре үткәрелде. Дәрестә укучылар аның тормыш юлы, иҗаты һәм әсәрләре белән таныштты.



2. 19 нчы октябрь көнне безнең мәктәп укучылары, укытучылары, әти-әниләре, мәктәп администрациясе вәкилләре Бөтендөнья күләмендә үткәрелүче "Татарча диктант Яз" акциясендә катнашты. Татарча диктат язуның максаты- татар телендә хатасыз язарга өйрәтү, әдәби татар телен кулланучыларның даирәсен арттыру, орфографик һәм грамматик хаталарны тикшерүгә корылган иде. Бу чарада 30 кеше катнашты. Иң яшь катнашучыга 15 яшь, иң олысына-55 яшь иде. Текстны Габдулла Кариев исемендәге яшь тамашачы театры артисты Рузанна Хәбибуллина укыды.



3. 21-23 нче октябрь көннәрендә республика күләмендә “Ел лидеры-2019” конкурсы үткәрелде. Бу конкурста безнең мәктәптән 9Б сыйныф укучысы Айвазян Вера катнашты. Ул үзенең лидерлык сәләтләрен, волонтерлык һәм җәмәгать эшендәге нәтиҗәләрен тәкъдим итте. Өч көнлек ярыштан соң Вера “Туган җиргә мәхәббәт” номинациясендә җиңү яулады. Алга таба да Айвазян Верага уңышлар телибез!









**Редколлегия:**

**Касыймова Гөлнур Наил кызы**

**Әмирхан Еники, 23.**
**Тел: 8 (843) 236-24-12**
**Сездән язмалар көтеп калабыз!**